**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18



**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«18» февраль, 2020 ел № 113

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы территориясендә муниципаль маршрутлар буенча пассажирлар һәм багаж ташуны даими гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны каплау максатларында пассажир йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2019 елның 14 февралендәге 266 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсе, Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең 2020 елга Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетын көтү йомгаклары һәм 2021 елга Татарстан Республикасы финанс, казначылык һәм салым органнарының бурычлары буенча уртак коллегиясенең 2020 елның 04 гыйнварындагы ПР-3 номерлы беркетмәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның 14 февралендәге 266 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы территориясендә муниципаль маршрутлар буенча җайга салына торган тарифлар буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга бәйле эшләр башкаруга чыгымнар өлешен каплау максатларында йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2. «Субсидияләр бирү шартлары» 3 өлешенең 3.1 пунктындагы 6 абзацында «салымнар һәм җыемнар турында» сүзләреннән соң «һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына башка түләүләрне» сүзләрен өстәргә;

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (http:/ www.-pestreci.tatarstan.ru һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми

порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары А.С. Шәйхесламовка йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе А.В. Хәбибуллин